**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Иске Кората авыл җирлеге**
**Советы**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Старохурадинского**
**сельского поселения**
**Алькеевского муниципального**
**района**

Адресы: 422898, РТ, Сиктерме-Хузангай а[illegible],
Мектеп ур., 15 Тел/факс: (84346) 73-4-03

Адрес: 422898, РТ, с. Сиктерме-Хузангаево, ул.
Школьная, 15 тел/факс: ( 84346) 73-4-03

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 21 июне 52№

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлегенең 2021 елның 1 декабрендәге "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Иске Кората авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында" 31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль

законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 19 пункты, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Иске Кората авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Иске Кората авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә (2022.04.02, 44№ редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 бүлектә:

6.1 пунктта «урынбасарын» сүзен төшереп калдырырга;

6.2 пунктындагы 4 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан һәм (яисә) региональ порталларыннан файдаланмыйча, контроль рәвешендәге нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә, дәүләт һәм башка саклана торган сер турында 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясының 2 өлеше нигезендә, дәүләт һәм закон белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, контрольлек рәвешендәге дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан һәм (яисә) региональ порталларыннан файдаланмыйча, шикаятьне карауга вәкаләтле зат тарафыннан тапшырыла.»

6.3 пунктының 2 абзацын төшереп калдырырга;

6.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Контроль (күзәтчелек) органы карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять контрольдә тотыла торган зат үз хокукларын бозу турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин."

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (https://alkeevskiy.tatarstan.ru/).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Кората авыл җирлеге башлыгы: И.В.Кудряшов